**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2252**
**15.05.2020**

2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 бүлекнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41, 53, 55 статьялары, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 15 маендагы
2252 номерлы карарына
кушымта

2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең
«Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Мәдәни-массакүләм, тамаша һәм спорт чаралары оештыру буенча хезмәтләр | | | |
| 1. | Театральләштерелгән һәм тематик бәйрәм программасы (көзге бал, яңа ел, чыгарылыш кичәләре һ.б.) | кеше/сәгать | 250,00 |
| 2. | «Күңел ачу уен программасы», «Дискотека» | кеше/сәгать | 70,00 |
| 3. | Театральләштерелгән һәм тематик бәйрәм программасы | кеше/сәгать | 70,00 |
| 4. | Иҗат мастерское | кеше/сәгать | 80,00 |
| 5. | Конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашу өчен оештыру взносы | кеше | 250,00 |
| II. Үстерү хезмәтләре | | | |
| 1. | «Стажерлар мәктәбе» программасы | 1 дәрес/1 кеше | 116,67 |
| 2. | «Әни белән бергәләп» программасы | 1 дәрес/1 кеше | 187,50 |
| 3. | Төрле юнәлештә үстерү дәресләре | 1 дәрес/1 кеше | 200,00 |
| 4. | «Према» йога студиясе | 1 дәрес/1 кеше | 160,00 |
| 5. | Семинар (тренинг) оештыру һәм үткәрү | кеше/сәгать | 300,00 |
| III. Өстәмә хезмәтләр | | | |
| 1. | Костюмнар прокаты | 1 тәүлек | 600,00 |
| 2. | Фото, видео- һәм аудиоязма хезмәтләре | сәгать | 500,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова